ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

04.06.2024 ел Баулы шәһәре № 81

Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы түләнә торган Баулы муниципаль районының муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» карарының 1-нче кушымтасына үзгәрешләр кертү һәм аны яңа редакциядә кушымта буенча раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2024 елның 6 маендагы 300 номерлы «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы түләнә торган Татарстан Республикасы дәүләт учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» 2011 елның 14 июнендәге 477 номерлы Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарына үзгәрешләр кертү турында» карарына ярашлы, Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ :

1. Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы «Бердәм тариф челтәре нигезендә хезмәт хакы түләнә торган Баулы муниципаль районының муниципаль учреждениеләре хезмәткәрләренең хезмәт хакын арттыру турында» карарының 1-нче кушымтасына (Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең 2012 елның 10 декабрендәге 281 номерлы, 2013 елның 24 октябрендәге 252 номерлы, 2014 елның 22 гыйварындагы 18 номерлы, 2014 елның 31 октябрендәге 330 номерлы, 2015 елның 20 ноябрендәге 319 номерлы, 2016 елның 8 июлендәге 219 номерлы, 2017 елның 10 августындагы 350 номерлы, 2018 елның 15 гыйнварындагы 11 номерлы, 2021 елның 6 декабрендәге 213 номерлы, 2022 елның 30 декабрендәге 282 номерлы карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) үзгәрешләр кертергә һәм аны яңа редакциядә кушымта буенча расларга.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 июленнән үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләтергә.

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Л. Бакиров

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесенең
2011 елның 22 июнендәге 134 номерлы
карарына (Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының 2024 елның
4 июнендәге 81 номерлы
карары редакциясендә)
1-нче номерлы кушымта

Баулы муниципаль районы бюджет өлкәсе хезмәткәрләренең хезмәт хакы буенча Бердәм тариф челтәренең тариф коэффициентлары һәм тариф ставкалары (хезмәт хакы)

| Бердәм тариф челтәренең түләү разрядлары | Тариф коэффициентлары | Тариф ставкалары (окладлар), сум |
|---|---|---|
| 1 | 1,0 | 19 242,0 |
| 2 | 1,0126 | 19 484,0 |

| | | |
|---|---|---|
| 3 | 1,0256 | 19 735,0 |
| 4 | 1,0381 | 19 975,0 |
| 5 | 1,0521 | 20 245,0 |
| 6 | 1,0656 | 20 504,0 |
| 7 | 1,0802 | 20 785,0 |
| 8 | 1,0942 | 21 055,0 |
| 9 | 1,1083 | 21 326,0 |
| 10 | 1,1233 | 21 615,0 |
| 11 | 1,1379 | 21 895,0 |
| 12 | 1,1535 | 22 196,0 |
| 13 | 1,1691 | 22 496,0 |
| 14 | 1,1846 | 22 794,0 |
| 15 | 1,2008 | 23 106,0 |
| 16 | 1,2174 | 23 425,0 |
| 17 | 1,2340 | 23 745,0 |
| 18 | 1,2512 | 24 076,0 |

Искәрмә: җитәкче урынбасарының тариф ставкасы (окладың) күләме тиешле җитәкченең тариф ставкасыннан (окладың) 1 - 2 разрядка түбәнрәк билгеләнә.